КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 март г.Казань № 371

Даими яшәү урыныннан мәҗбүри киткән һәм Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч массакүләм рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына мөлкәт булдыру өчен бер тапкыр бирелә торган түләү бирү чараларын финанс белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетына финанс ярдәме күрсәтүдән файдалану кагыйдәләрен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Даими яшәү урыныннан мәҗбүри киткән һәм башка территорияләргә ашыгыч массакүләм рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына күченү чараларын гамәлгә ашыру турында» 2022 елның 21 октябрендәге 1876 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими яшәү урыныннан мәҗбүри киткән һәм Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч массакүләм рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына мөлкәт булдыру өчен бер тапкыр бирелә торган түләү бирү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 18 гыйнвар, 17 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Даими яшәү урыныннан мәҗбүри киткән һәм Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч массакүләм рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына мөлкәт булдыру өчен бер тапкыр бирелә торган түләү бирү чараларын финанс белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетына финанс ярдәме күрсәтүдән файдалану кагыйдәләрен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 29 март, 371 нче
карары белән расланды

Даими яшәү урыныннан мәҗбүри киткән һәм Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч массакүләм рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына мөлкәт булдыру өчен бер тапкыр бирелә торган түләү бирү чараларын финанс белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетына финанс ярдәме күрсәтүдән файдалану
кагыйдәләре

1. Бу Кагыйдәләр даими яшәү урыныннан мәҗбүри киткән һәм Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч массакүләм рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына мөлкәт булдыруга бер тапкыр бирелә торган түләү бирү өчен «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе (алга таба – Фонд) тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан күрсәтелә торган финанс ярдәменнән (алга таба – шул ук эзлеклелектә бер тапкыр бирелә торган түләү, финанс ярдәме) файдалану тәртибен билгели.

2. Фонд акчасы исәбеннән финанс ярдәме Федераль казначылык Татарстан Республикасы буенча идарәсендә (алга таба – Казначылык) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына ачылган керемнәрне исәпкә алу һәм бүлү операциясен гамәлгә ашыру һәм чагылдыру өчен Татарстан Республикасы бюджетының казначылык счетына керә.

3. Бу Кагыйдәләрнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга бүлеп бирелә торган финанс ярдәмен тоту Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылыктан акча керү турында мәгълүмат алынган көннән биш эш көне эчендә аларны Министрлыкка үзе тапшырган бер тапкыр бирелә торган түләү чыгымнарын финанслау хакындагы заявкалары буенча күчерә.

5. Министрлык үзенең тиешле счетына акча кергән көннән биш эш көне эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына гражданнарның кредит оешмаларында ачылган шәхси счетларына бер тапкыр бирелә торган түләүне күчерү өчен касса чыгымына заявка бирә.

6. Министрлык атна саен Фондка түбәндәгеләрне, «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыру» автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан файдаланып, электрон рәвештә яки кәгазь чыганакта («Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыру» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы ярдәмендә хисап бирү өчен техник мөмкинлекләр булмаганда) Татарстан Республикасы белән Фонд арасында төзелгән финанс ярдәме күрсәтү турындагы килешүдә билгеләнгән тәртиптә тапшыра:

а) Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында хисап;

б) бер тапкыр бирелә торган түләүләр турында хисап.

7. Агымдагы елда финанс ярдәменең файдаланылмый калган өлеше Фондка кире кайтарылырга тиеш.

8. Тапшырыла торган хисап мәгълүматлары дөрес булмаган һәм финанс ярдәменнән максатчан файдаланмаган өчен Министрлык Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

9. Финанс ярдәменнән максатчан файдалануны контрольдә тоту Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.